وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا


Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+


# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№20 (163). 16 ноябрь 2012 / 2-мөхәррәм-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



ГАРИФУЛЛА ишан ГАЙНУЛЛИН ▷2◁



МӘКТӘПЛӘРДӘ хиҗап тыелырмы? ▷3◁



РОССИЯДӘ хезмәтнең торышы ▷4◁

## ХӘЕРЛЕ ЕЛЛАР БУЛСЫН!

*Яңа ел - үткән елга билгеле бер нәтиҗәләр ясау һәм киләчәккә ниятләрне билгеләүбарлау вакыты җитте. Һиҗри ел исәбе буенча 14 ноябрь көнне кояш баю белән 1434 ел башланды. Яңа елны башлап җибәрүче мөхәррәм ае мөселманнар өчен аеруча әһәмияткә ия. Мөхәррәм ае теләсә нинди ызгыш-талашлар, низаглар тыелган 4 айның берсе (рәҗәп, зөлкагдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм). Бу айда һәрбарчабызның күңелләре бары тик мәрхәмәт һәм шәфкатьлелек белән генә тулган булырга тиеш.*

*Коръәни-Кәримдә әлеге изге айның фазыйләтләренә зур урын бирелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үзенең бер хәдисендә: "Рамазан уразасыннан соң иң фазыйләтле ураза мөхәррәм аенда тотылган уразадыр", - дип билгеләп үтә. Икенче бер хәдисендә: "Мөхәррәм аенда бер көн ураза тоткан кешегә 30 көн ураза тоткан кадәр савап язылыр", - ди. Мөхәррәм аенда Гашура көне булуы аның кыйммәтен, мөһимлеген тагын да арттыра. Гашура көнендә кылган игелекле гамәлләр һәм мөхәррәм аеның 9, 10 һәм 11 нче көннәрендә тоткан уразалар өчен Аллаһы Тәгалә зур саваплар насыйп итәр, иншалла.*

*Әһәмияте буенча Рамазаннан соң икенче урында торган мөхәррәм аенда без аеруча татулыкка омтылырга, гамәлләребезне игелекле итәргә, кыен хәлдә калучыларга ярдәм кулы сузарга һәм аларның хәлләренә керергә тиешбез.*



*Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешергә теләп, елны яхшы эшләрдән башлыйбыз икән, алдагы көннәребез дә, иншалла, матур гамәлләр, чиста ниятләр белән тулыр, һәм, нәтиҗә буларак, иманыбыз да ныгыр.*

**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## ҺИҖРИ ИСӘП БУЕНЧА ЯҢА ЕЛ

**Кешелек дөньясының иң бөек вакыйгасы, һишчиксез, Аллаһ илчесенең (сгв) Мәккәи-Мөкәррәмәдән Мәдинәи-Мөнәввәрәгә һиҗрәтедер.**

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (сгв) Мәккәдә Аллаһы Тәгаләнең динен таратканда Мәдинәдә дә бик күп кешеләр Исламиятне кабул итәләр. Алар Мәккәгә Кәгъбәне зиярат итү өчен килгәндә "Акабә" дигән җирдә Пәйгамбәребез (сгв) белән күрешеп иман китергәннәр. Мәккәдә яшәүче мөселманнар белән Пәйгамбәребез дә кяферләрнең золымыннан газап чиккән. Сәхабәи-Кирамның һәммәсе дә җәфалар аркылы үткән, ләкин берсе дә иманыннан ваз кичмәгән. Туктаусыз җәфалаулар сәбәпле, Пәйгамбәребез (сгв) сәхабәләренә Аллаһ әмере белән Мәдинәгә һиҗрәт (күчәргә) итәргә рөхсәт биргән.

Шулай итеп, милади исәп буенча 622 елның мөхәррәм аеннан башлап, мөселманнар яшерен рәвештә Мәдинәгә һиҗрәт кыла башлаганнар. Аллаһы Тәгаләнең дине буенча яшәү өчен йортларыннан, малларыннан, һавасын сулап туып үскән җирләреннән аерылып, күп кенә мөселманнар Мәдинәгә күчеп киткән. Хәзрәти Госман (рг) һәм хәзрәти Гомәр (рг) дә һиҗрәт иткәннәрнең җитәкчелегендә булганар. Кайбер мөселманнар күчәргә теләсәләр дә, Мәккә кяферләре аларның күченүләренә киртә корган.

Мөселманнарның Мәдинәгә һиҗрәт кылып, анда туплануларына чик куя алмаган Мәккә кяферләре хәзер инде Пәйгамбәребезнең (сгв) Мәдинәгә күчеп китә алмавына һәртөрле чаралар эзләгән.

Шулай итеп, кяферләр бер көнне "Даруннәдвә"дип аталган өйдә җыелганнар. Кяферләрнең кайберләре Пәйгамбәр әфәндене тоткында тотарга, кайберсе ерак җирләргә сөргенгә җибәрергә, дигән фикер әйткән. Әбу Җаһил исә Аллаһ илчесен (сгв) үтерү турындагы фикерен алга сөргән. Башкалар да: "Юк итүдән башка чара калмады", - дип берләшкәннәр. Һәм: "Һичшиксез, үтерергә!" - дип карар кылганнар. Кяферләр Пәйгәмбәребезнең (сгв) өен уратып алганнар. Өйдән чыгуын көткәннәр. Күренүгә, шундук үтерәчәк булганнар. Пәйгәмбәребез (сгв) бу төндә үз ятагына хәзрәти Галине яткырган. Үзе Коръәни-Кәримнең "Ясин" сүрәсен укый-укый өен уратып алган кяферләр арасыннан чыгып киткән. Һичбер кяфер аны күрмәгән. Аллаһ аларның күзләрен күрмәс, танымас хәлгә китергән ки, һичберсе пәйгәмбәребезне (сгв) күрмәгәннәр. Кяферләр өйгә керү белән, Пәйгамбәребез (сгв) урынында хәзрәти Галине күргәч, шаккатканнар.

Милади белән 622 елның Рабигуль-Әүвәл аенда сөекле Пәйгәмбәребез (сгв) хәзрәти Әбу Бәкер белән бергәләп Мәккәи-Мөкәррәмәдән аерыла. Мәшәкатьле һәм могҗизалар белән тулы бер юлдан соң, Мәдинәи-Мөнәввәрәгә килеп җитәләр. Мәдинәдә Аллаһы Тәгаләнең соңгы шәригате булган Ислам көч алып, зурая һәм дәүләткә әйләнә.

Сөекле Пәйгамбәребезнең (сгв) бу һиҗрәте хәзрәти Гомәр (рг) хәлифәлеге вакытында һиҗри календарьның беренче елы булып кабул ителгән, ел башы итеп исә мөхәррәм ае санала башлаган.

Шулай булгач, мөселманнарның ел башы мөхәррәм ае белән башлана. Мөселманнар яңа елга мөхәррәм ае белән аяк басалар.

Һиҗрәтнең һәм яңа елыбызның рухын яңадан тоеп, бозылган калебләребезне яңадан тәртипкә китереп, Исламны яңадан көн тәртибенә кертеп, яңадан Хак әһелләренә әверелеп, Аллаһның сөекле бәндәләре булып яшәргә насыйп әйләсә иде.

***Руслан хәзрәт МОРТАЗИН, Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые, Актаныш Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы***



## ЯҢАЛЫКЛАР

### "ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ" УЗДЫ

**13 ноябрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Коръән елы уңаеннан чираттагы чара уздырылды.** Мөслимәләр һәм Коръән турында "Коръән хозурында хатын-кыз" дип аталган "түгәрәк өстәл" үткәрелде.

Чарада мөфтиятнең нәшрият бүлеге мөдире, Тынычлык мәчете имам-хатыйбы Камил хәзрәт Сәмигуллин, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәрләре Айдар Хәйретдинов, Ләйлә Алмазова, җәмәгать эшлеклесе Әлмира Әдиятуллина, Гадел мәчете мәгаллимәсе Фәния абыстай һ. б. катнашты.

"Түгәрәк өстәл"дә сөйләшү хатын-кызларга карата шәригать таләпләре һәм мөслимәләрнең бүгенге җәмгыятьтәге роле турында барды. Шулай ук татар дин әһелләренең мөслимәләргә багышланган хезмәтләре барланды.

### АПАНАЙ МӘЧЕТЕНДӘ ӘМИРХАНОВЛАР ҖЫЕЛДЫ

**15 ноябрь көнне Казанның Апанай мәчетендә татар халкы тарихында зур эз калдырган нәсел варислары җыелды:** пәнҗешәмбе көнне мәчеттә узган кичәгә Әмирхановлар килде. Әлеге чараны Апанай мәчете "Иман" мәркәзе, "Мөслимә" иҗтимагый оешмасы уздырды.

### ЗӘКЯТ ТУРЫНДА ЛЕКЦИЯЛӘР УКЫЛДЫ

**10 ноябрьдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендәге "Зәкят" хәйрия фонды Теләчедә, район мөхтәсибәте белән берлектә, авыл имамнары өчен махсус лекцияләр оештырды.** "Зәкят" хәйрия фонды консультанты Нурислам хәзрәт Ибраһимов имамнарга зәкят турында сөйләде һәм аларның сорауларына җавап бирде. Лекцияләрне 20 имам тыңлады.

"Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин әйтүенә караганда, зәкят темасына багышланган лекцияләрне, семинарларны Казан һәм авыл имамнары өчен даими үткәрү күздә тотыла. Фонд белгечләре авылларга махсус барып, Исламның биш баганасының берсе - зәкят турында аңлатачаклар.

### МӘДРӘСӘГӘ ХӘЙРИЯ ЯРДӘМЕ КҮРСӘТЕЛГӘН

**Бөгелмә шәһәренең Үзәк мәчетендәге "Шәфкать" үзәге Урыссу мәдрәсәсенә хәйрия ярдәме күрсәтте:** читтән торып укучыларга файдалану өчен савыт-саба, урын-җир кирәк-яраклары җыеп тапшырды.

Район мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйруллин хәбәр иткәнчә, шәһәрдә ярдәм күрсәтү үзәге барлыкка килгәнгә бер елдан артык. Үзәктә мохтаҗлар өчен киемнәр, савыт-сабалар, урын кирәк-яраклары кабул итәләр. Шулай ук мохтаҗлар өчен кирәк-яраклар шәһәрнең һәм районның һәр мәчетендә һәм "ЭССЕН" гипермаркетында кабул ителә. Әлеге кибеттә әйберләр җыю өчен махсус тартма куелган. Мохтаҗлар үзәккә һәрвакыт ярдәм сорап мөрәҗәгать итә ала.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**


**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# ГАРИФУЛЛА ишан ГАЙНУЛЛИН

(1894-1984)

(Татарның соңгы ишаны)

**Гайнуллин Гарифулла Гайнулла улы 1894 елның 24 мартында Буа районының Аксу авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. 1909-1914 елларда үз авылының башлангыч дини мәктәбендә укый.**



20 яшендә ул авылыннан Донбасска күмер чыгару шахталарына акча эшләргә китә. Тиздән, 1915 елда, патша армиясенә чакырыла. I Бөтендөнья сугышында катнаша. Варшава шәһәре янында барган бәрелештә каты яралана. Госпитальдән терелеп, 1917 елны туган авылына кайта.

Илдә Совет хөкүмәте урнашканнан соң, 1918 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Ак гвардиячеләр белән сугышларда катнаша. Царицыно (Волгоград) янында 1919 елның гыйнварында каты яралана һәм Деникин армиясенә әсирлеккә төшә. Әсирлектә вакытта Дондагы Ростов (Ростов-на-Дону) шәһәрендәге лазаретта ята. Тиздән – 1920 елның гыйнварында Кызыл Армия отрядлары ярдәмендә азат ителә, Будённый армиясенең 62 кавалерия полкына кушылып, телефонист булып хезмәт итүен дәвам иттерә.

1921 елның май аенда, демобилизациядән соң, туган авылына кайта. 27 яшендә авылдашы Нурмөхәмматова Разия Нурмөхәммәт кызына өйләнә. Укый-яза белүче, авылдашларыннан ихтирам казанган Гарифулла Гайнуллин 1923 елда авыл советы әгъзасы, 1924 елда Аксу кооперациясенең идарә әгъзасы, ә 1927 елда Аксу кредит оешмасының идарә әгъзасы итеп сайлана.

Авылдагы авыр тормыш, хәерчелек аны 1930 елда Мәскәү өлкәсенең Шатура шәһәренә акча эшләргә китәргә мәҗбүр итә. Анда ул берничә ел төзелеш эшләрендә эшли. 1933 елда Аксу авылына кайта. Үзенең шәхси хуҗалык кереме хисабына тормышын алып бара. Ул вакытта Аксу авылы халкы яшелчә, күбесенчә, кишер үстереп, аны сәүдә итеп яши торган була.

1934 елда авылдагы авыр икътисади хәл аны гаиләсе белән Үзбәкстанның Ташкент шәһәренә акча эшләргә китәргә мәҗбүр итә. Анда ул тимер юлга каравылчы булып урнаша. Бер ел чамасы эшләгәч Махачкала шәһәренә хатынының туганы, Зәйнулла ишан Рәсүлев укучысы – Баязид ишан Хәйруллин янына күчә. Дагстан балык трестында бригадир булып эшли. Бу елларда Гарифулла Гайнуллин Баязид ишанның мөриде була һәм үзен тарикатькә багышлый.

1937 елда ул яңадан туган авылына кайта, колхозда һәм үз хуҗалыгында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елның апрелендә Гарифулла хәзрәт Совет армиясе сафларына алына. Казанда хәрби хезмәткә өйрәнә һәм Сталинград шәһәрен сакларга җибәрелә. Канкойгыч сугышта берничә тапкыр каты яралана, озак кына госпитальдә дәвалана, соңрак инвалидлык алу сәбәпле, хәрби хезмәттән азат ителә. Туган авылына кайтып, шәхси хуҗалыгында эшләвен дәвам иттерә, орлыклар сату белән шөгыльләнә һәм тарикать юлында зур тырышлык куя, мөршид дәрәҗәсенә ирешә.

1951 елда Гарифулла хәзрәт гаиләсе белән Казанга күчеп килә. “Химчистка” артелендә каравылчы булып эшли. 1956 елның октябрендә пенсиягә чыга.

Казанда Гарифулла хәзрәт атна саен яшерен рәвештә үзенең шәкертләрен җыя, алар бергәләшеп хафи һәм җахри зекерләрен әйтә торган булалар. Аның мөридләре саны уннан артмый – аларның күбесе олы яшьтәге кешеләр була. Гарифулла хәзрәт даими рәвештә Казанның Мәрҗани мәчетенә йөри, өшкереп күп кешеләрне дәвалый. Аның янына һәрдаим кешеләр киңәш һәм ярдәм сорап киләләр. Эчке эшләр органнары тарафыннан аның эшчәнлеге һәрвакыт каты күзәтүдә була.

Гарифулла хәзрәтнең иң якын көрәштәшләренең берсе – Габделханнан хәзрәт Сафиуллин (1973 елда ахирәткә күчә). Ул да шулай ук Баязид Хәйруллин шәкерте була. Казанда яши, ишан буларак таныла.

1957 елда Гарифулла хәзрәт СССРда яшәүче кешеләрнең бик сирәгенә насыйп булган Мәккә шәһәренә барып, хаҗ кылу бәхетенә ирешә.

Гарифулла хәзрәт 1984 елның 6 апрелендә 90 яшендә дөньядан китә. Ул Казан шәһәренең Яңа татар бистәсендәге мөселман зиратына күмелгән. Г.Гайнуллин үзененең варисы итеп Буа шәһәрендә яшәүче Камил Бикмөхәммәтовны калдыра (1922-2000).

Гарифулла хәзрәт Разия ханым белән 13 бала тәрбияләп үстерә (Хәмзә, Мәсхүт, Исламия, Суфия, Камил, Әхәтҗан, Кәүсәр, Әминә, Рокыя, Зөбәрҗәт, Җәүһәрия, Кәүсәр), аларның күбесе балачакта ук үлә. Бүгенге көндә Казанда аның 3 кызы яши: Зөбәрҗәт (1928), Җәүһәрия һәм Кәүсәр (1930).

Татар халкының соңгы ишаны Гарифулла хәзрәт үз заманының абруйлы кешеләреннән булып, илебездәге авыр дәһрилек (атеизм) елларына да карамастан, ислам динен саклап калуга үзеннән зур өлеш кертә. Замандашлары Гарифулла хәзрәтне якты-нурлы йөзле, югары әхлак иясе һәм диндар кеше буларак, тирән ихтирам белән искә алалар, аның рухына дога кылалар.

**Рәшид МАЛИКОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**Буа мәдрәсәсе директоры**

*Зиннур ХӨСНИЯР*

# ГАРАСАТ

## *Балачак хатирәләре Адәм пәйгамбәр балаларын гомер буе озата бара...*

**Хәтерлим, без балачакта кемнәрдер зыяраттагы күмү өчен әзерләп куйган әйберләрне пыран-заран китергән һәм андагы көрәкләрне урлап киткәннәр иде. Без, әлеге хәбәрне беренче булып ишеткән малай-шалай, инде күптән авыл артындагы зыярат янында идек. Шук булсак та, шаян булсак та, әниләр әйтмешли башсыз булсак та, без теләсә ниди гамәл кыла ала торган башкисәр малайлар да ул чакта зыяратны мыскыл итүне бик авыр кабул иткән идек! Кайда мыскыл итү ди, кешеләр хәтта аның эчендәге котырып үскән печәнне чабарга да җөрьәт итмиләр иде!**



Безгә каршы бригадир Әдһәм абый очрады, арттан исә колхоз рәисе Рәшит Бариевич куып җитте. Әдһәм абый аңа зыярат коймасы эчендәге корылманы ватып, күмү өчен кирәк-ярак коралларны, калган ләхет такталарын урлап китүләре хакында әйтте. Рәшит Бариевич җитәкче буларак, атеистыр кебек тоела иде. Өстәвенә коммунист бит әле! Тик ул зыярат ягына карады да, бары: "Тәмуг кисәүләре! Җәһәннәм утында яначаклар әле!" - дип кенә куйды. Юк, ул берәүне дә каргамады да, сүкмәде дә, болай гына, пышылдап кына әйтте. Колхоз рәисе генә булуга карамастан, бик интеллигент кыяфәтле, үз-үзен тотышы, кием-кыяфәте белән дә бик зур түрәгә охшап тора, беркайчан кычкырып сүкмәс, чын мәгънәсендә әүлия кеше иде! Ләкин сүзе белән йомшак җиреңә бик тиз утырта да белә иде. Хөрмәткә лаеклы җир профессоры, шәп педагог иде Рәшит Бариевич Зәбиров. Безнең өчен ул вакытта дөньяда аннан да зуррак түрә юк иде, билгеле. (Рәшит Бариевич Зәбиров шуннан соң, Рөстәм Миңнеханов Биектауда хакимият башлыгы булып эшләгәндә, аның киңәшчесе булып торды. Президент аны әле дә еш искә алып сөйли дип ишеткән бар). Без аңа үзебезнең шигебезне белдерергә ашыксак та, ул шулай дигәч, тынып калдык. Тәмуг уты диде бит! Без әби-бабайлардан ишетеп белгән нинди куркыныч сүз ләбаса!..

Безнең шик хак булып чыкты, Рәшит абый да алдан белеп торган кебек: күрше авылдагы "Өрәкләр" дигән кушамат йөрткән кешеләрнең йорт-курасы нәкъ бер атнадан соң янып көлгә әйләнде. Пожарда бер нарасый бала һәм карт әниләре янган икән дип сөйләделәр!.. Без дә бит нәкъ менә шул кичне зыяраттан бездән өч яшькә олырак "өрәкләр" малаеның нәрсәләрдер күтәреп чабып чыгып барганын күреп калган идек...

Хәтирәләр бер чылбырдагы тутыкмас төймәләр кебек. Минем әни алтмыш биш яшендә намазга утырды (биш бала табып үстергән ананың, әлбәттә, яшьрәк чакта догалар өйрәнергә вакыты да, мөмкинлеге дә юк иде). Һәм безнең барыбызны да шаккаттырып, гарәп хәрефләреннән дәресләр ала торгач, абыстай ук булып китте. Шулай беркөнне ул бер мәҗлестән бик кәефе китеп кайтты, һәм: "Бүтән укып йөрмим, үзем өчен генә, өйдә генә укырмын, - дип куйды. - Алла кабул итсен!.." Без намазга басканнан соң яшәреп киткән әниебезнең мондый төшенкелеккә бирелгәнен күргәнебез юк иде, бу хәлгә, әлбәттә, аптырап калдык. Баксаң, Коръән мәҗлесендә Казаннан кайткан янә бер бик белдекле абыстай булган икән, шул хатын элеккеге авылдашларын: "Сез бу сүзне дөрес әйтмисез, сез болай итмисез, тегеләй итмисез!" - дип, бар мәҗлеснең ямен җибәргән. Картлык көннәрендә Ходай Тәгаләгә сыгынуның иң дөрес юлына баскан әбиләрне мыскыл итеп, алардан кычкырып көлгән булган икән. Әнинең шуңа бик тә кәефе киткән! Һәм ул чынлап та куркуга калып, бәлки, мин чыннан да дөрес түгелдер дип, хафалана башлагач, әнинең сорауларын кәгазьгә язып алдым да, Мәрҗани мәчетенә махсус барып, шулар хакында сөйләшкәнем хәтердә. Указлы имам: "Әниеңнең бар укыганы һәм кылганы дөрес! Курыкмасын, борчылмасын, дәвам итсен!" - дип әйтеп-аңлатып җибәрде. Мин боларны бәйнә-бәйнә әнигә кайтып сөйләгәннән соң гына ул бераз тынычлангандай булды.

Бу хәлләргә шактый вакыт узды инде. Ләкин бер авылдаш картның шундый бәхәсләргә кагылышлы рәвештә гади генә, әмма үтемле итеп әйткән сүзләре һаман күңелдән китми: "Ходай Тәгаләгә якынаюда һәркемнең үз сукмагы!" - дияргә ярата иде ул. Бүген дә, әлеге сүзләр искә төшкәндә, мин сокланып: "Фәлсәфәче булган икән бу гади генә авыл карты Әхмәдулла агай!" - дип уйлап куям. Бүген ислам динендә имам дәрәҗәсенә ирешкән кайбер бәгъзе адәмнәрнең дә мондый фәлсәфәгә барып җитә алганнары юклыгын тормыш һәрдаим раслап, хаклап торадыр кебек, миңа калса!

Кызык карт иде ул. Белмим, кайсы сыйныфта укыган чагым булгандыр, шулай бер көн чират көтүеннән кайтып киләм. Кич җиткән, сарыкларны авыл башына чаклы куып алып мендем дә, үз ирекләренә җибәреп, капка төбендә кәҗәсенең көтүдән кайтканын көтеп утырган Әхмәдулла карт янына килеп утырдым. "Ничек, безнең мур кыргыры кәҗә бик интектермәдеме? Суслангерга җибәрәм әле мин аны, болай теңкәгә тия торган булса! Көтүче чыбыркысын да санламый ул, мәлгунь!" - дип сүгә башлады Әхмәдулла карт. Әхмәдулла картларның мур кыргыры кәҗәсен авылда белмәгән кеше юктыр. "Суслангер" дип әйтүе шартлы рәвештә, Мари ягында Суслангер лагере булган дип ишетеп белә идек. Әхмәдулла картны, - шунда булып кайткан кеше, - ачы язмышы фәлсәфәче ясагандыр да әле, бәлки, дип уйлый идем мин. - Кәҗә акыллы халык ул, көтү "характырын" аңлый торган хайван. Кешедән мең тапкыр акыллырак: чыбыркы белән эләктерсәләр эләктерәләр аңа, ләкин ул барыбер көтү "характырына" буйсынмый торган халык... кәҗә халкы, - дип сүзен дәвам итте Әхмәдулла карт. - Көтү "характырына" кешеләр генә буйсына ул. Без гомер буена көтү булып яшәдек. Бер Сталин гына ничә миллионның башына җитә алмас иде шулай булмаса! Ә кәҗә буйсынмый ул. Кәҗә "характырлы" хайван ул патамушты!".

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Мәктәпләрдә хиҗап тыелырмы?

**Октябрь урталарында Ставрополь краеның Кара түбә авылындагы гомумбелем бирү мәктәбе директоры өч укучыга мөслимәләрнең баш киеме - хиҗап белән бу уку йортына килүне тыйган.**



Әлеге вакыйга ил күләмендә яшен тизлегедәй таралды, хәтта президентның үзенә дә бу турыда аңлатмалар бирергә туры килде.

Ни өчен өч кызның хиҗап киеп йөрүе 140 миллион кеше яшәгән Россиядә шулкадәр киң фикер алышулар темасына әйләнде соң? Чөнки, практика күрсәткәнчә, нәкъ менә хиҗап проблемасы хәзерге дөньяви җәмгыятьнең үзәк проблемаларының берсенә әверелә түгелме? Ник дигәндә, Ставрополь низагыннан башланып киткән дискуссия дөньявилык, динилек, либеральлек, мультикультуризм, гендер һәм кеше хокуклары кебек күп кенә мәсьәләләрне алгы планга чыгарды.

## Хиҗап - феминизм символымы?

Кайбер мөселман феминисткалары (шул ук вакытта, бу мөселман яулыгын аңлы рәвештә үзләре сайлап алган башка мөселман хатын-кызлары да) хиҗапны хатын-кызларны кимсетү традициясе итеп түгел, ә киресенчә, аны аларның эмансипациясенең (автономиясенең) заманча альтернатив ысулы итеп кабул итәләр. Шуңа да, шул мәсьәләгә ачыклык кертеп китәргә кирәк, хәзерге дөньяви мохиттә хиҗап нәрсә соң ул: традиционлыкмы, әллә заманчалыкмы? Бу сорауга җавап үзеннән-үзе үк күренеп тора.

Көнбатыш феминизмының хиҗапка хатын-кызларны кимсетергә тырышу элементы итеп карап, аңа тискәре караштa булуына да карамастан, күп кенә мөселман илләрендә, һәм шул ук вакытта, АКШ һәм Европа илләрендә дә мөселман, Ислам феминизмы үсеш ала бара. Мөселман феминисткалары, бер яктан, Көнбатыш феминизмына, аның евроцентристик карашлары аркасында аңа тискәре карыйлар; ә икенче яктан, шәркый җәмгыятьләрдәге тормыш рәвешен, аның патриархальлекләре аркасында тәнкыйть итәләр. Андый тормыш рәвеше, алар фикеренчә, Исламның башлангыч рухына каршы килә. Мөселман феминисткалары, Исламда хатын-кызлар өчен зур эмансипацион мөмкинлеге салынган дип исәплиләр. Бу - аларның дини тәртибен саклап калу белән бергә аларга хатын-кыз ихтыяҗларын да чынбарлыкка кертеп җибәрергә мөмкинлек бирә. Әлегә бар мөселман феминисткаларының да бердәмлеге турында сөйләп булмый. Мәсәлән, Көнбатышның кайбер феминисткалары Ислам традицияләре корылмасын җимерү юлыннан киттеләр. АКШның билгеле феминисткасы, Виргиния университеты профессоры Әминә Вәдүт Нью-Йоркның бер чиркәвендә (бер генә мәчет тә аңа урын бирергә мөмкинлек бирмәгән) имам булып гендер яктан катнаш аудиториядә җомга намазы үткәргән. Мисыр, Төркия мөселман хатын-кыз активисткалары исә хатын-кызларның ролен актуальләштерүне мөселман традицияләре корылмасын җимерү юлы белән түгел, ә төп дини чыганаклар нигезендә хатын-кызларның ролен яңа төр аңлаулар аша башкарырга тырышалар. Шуңа да шәрык илләрендә "феминизм" сүзен, гомумән, кулланмаска тырышалар, аның урынына күбрәк "мөселман активисткалары" турында сүз алып баралар.

Һәр очракта да, кыюрак булган мөселман эмансипациясе, һәм шул ук вакытта мөселман активлыгы да, шәһәр мохитенең яңа динилелеге өчен хас булган күренешләр. Мисыр белән Төркиядә дөньяви режимнар урнаштырылуга да карамастан, Каһирә һәм Истанбулның зыялы хатын-кызларының, ә алардан соң Европа мөселман хатын-кызларының да хиҗапны сайлап алу факты Көнбатыш феминисткаларында гаҗәпләнү тудырды.

Шуңа да, шәһәр мохитендә динилекнең чагылуы турында сөйләгән вакытта, теләсә нинди гомумиләштерүнең катлаулы эш икәнен истән чыгармаска кирәк. Мәсәлән, хәзерге Чечен Республикасында хиҗап публика киңлегендәге дресс-кодның хатын-кызлар өчен булган мәҗбүри өлешенә әйләнгән (чеченлыларның телевидениесендәге диктор хатын-кызларны исегезгә төшерегез). Гәрчә, Төньяк Кавказ турында сүз алып барган вакытта, гомумиләштерүләрне билгеле бер искәрмәләр белән эшләргә кирәк.

Үзәк Россиянең зур шәһәрләрендә (Мәскәүдә, Петербургта, Казанда, Түбән Новгородта һ. б.) шәһәр пространствосының чуарлыгы аркасында хәл күпкә катлаулырак. Шуның өчен анда мөселманнарның хиҗабы дингә рефлексив мөнәсәбәт нәтиҗәсе дә булырга мөмкин: аңлы рәвештә сайлап алу да, массакүләм мәдәният басымына җавап та, ата-аналар, ире һәм башка туганнары йогынтысы белән эшләнгән традицияләрне дәвам итү дә.

Соңгы елларда Казанда да, Мәскәүдә дә мөселманча яулык бәйләгән кызлар шәһәр берлегенең бер өлешенә әйләнде. Әлбәттә, динилекнең андый символы сизелми калмаска мөмкин түгел. Әмма дөньяви массакүләм мәгълүмат чаралары, кагыйдә буларак, бу образны каралатырга тырышсалар (үлемгә баручы шәһидәләр һ. б.), исламныкылар исә геройлаштыралар. Хиҗапны дәүләт учреждениеләрендә киеп йөрү хокукы турында сүз барган вакытта бу мәсьәлә аеруча кискен төсмер ала.

## Европа бу мәсьәләне ничек хәл иткән?

Россия - хиҗап проблемасы белән очрашкан бердәнбер ил түгел. Әле 1989 елда ук Крей дип йөртелгән француз шәһәрендә хиҗап киеп йөргән өчен өч мөселман укучысын мәктәптән куганнар. Нәкъ менә шул вакыйгадан соң Франциядә "яулык эше" дип үзенә күрә эш башланып киткән. Европа һәм Америка социологлары билгеләп үткәнчә, аннан соң башланып киткән дискуссия француз республикасы хакимияте системасының бар мәгънәсенә дә кагылып үткән: шул ук вакытта Франциядә социаль һәм гендер тигезлеге һәм либеральлек, республикачылык һәм мультикультуризмның чагыштырмасы мәсьәләләренә дә.

Мәсәлән, Йел университеты профессоры Сәйла Бәнхабиб 1989 елгы конфликтны бәян итеп: "Кызларның мәктәпкә яулык бәйләп килүләрендә җитди генә сәяси ишарә бар иде, - дип яза. - Андый гамәлләре белән алар, бер яктан, француз гражданнары сыйфатында вөҗдан ирегe хокукына дәгъва белдерүләрен күрсәтәләр иде. Ә икенче яктан - үзләренең мөселман һәм чыгышлары белән Төньяк Африкадан булуларын демонстрациялиләр иде". Нәтиҗәдә, Франциядә хиҗап дәүләт учреждениеләрендә тыелды.

Хәзерге демократик илләр нигезендә яткан ике мөһим принципның (вөҗдан ирегe һәм дәүләтнең диннән аерылуы) үзара бәрелешүе - бу мөселман баш киеменең идеологик көрәштә куәтле һәм катлаулы символына әйләнүенә сәбәп булды. Монда хиҗап кебек беренче карашка гади генә күренгән бу баш киеменең дөньяви мәктәп контекстына кертелүе дә үз ролен уйнады.

Төркиядәге кемалистик кануннар шулай ук хиҗап киеп дәүләт учреждениеләрендә, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында эшләүне тыеп, мөселманнарны кимсетә иде. Төрек Республикасындагы хиҗапка карата мондый мөнәсәбәт хәзерге Төркиягә нигез салучы Кемал Ататөрекнең нәкъ менә француз секуляр моделе - лаицизм тарафдары булуы белән бик җиңел аңлатыла.

Моның белән бәйле рәвештә, социологларның (World Values Survey челтәре) белешмәләренә караганда, хәзерге Төркиядәге көнбатышчылык тарафдарлары бернинди дә демократия яклы кешеләр түгел. Шул ук вакытта, Төркия мөселманнары, киресенчә, демократик принциплар өчен көрәшәләр. Моны лаицизмның дингә карата алып барган практикасының берничек тә демократик булмавы белән дә аңлатырга мөмкин.

Ләкин шундый сорау туа: андый каты сәясәт француз һәм төрек җәмгыятьләрендә ислам дине факторының көчәюен туктата аламы соң? Күрүебезчә, юк, туктата алмый. Төркия хакимиятенә 2003 елда Рәҗәп Таййип Әрдоган җитәкчелегендәге уртакул исламчылар килде. Сүз уңаеннан әйтик: алар Төркия өчен бервакытта да күрелмәгән икътисади үсеш, халыкара сәясәттә бу илнең роле артуын тәэмин итәләр. Һәм, шул ук вакытта, бу дәүләтнең дөньяви булуына кулларын сузмыйлар. Франциядә дә мөселман илләреннән килгән эмигрантлар бер дә кимемәде, шуңа да өстәп, Николя Саркозиның президентлыкка сайлаулар вакытында җиңелүенең мөмкин дип исәпләнгән сәбәпләренең берсе - аңа карата мөселман чыгышлы сайлаучыларның тискәре карашы дип атыйлар.

Әмма француз секуляр моделе, дөньяда булганнары арасында бердәнбере түгел. Дәүләтне чиркәүдән аерган күпкә йомшаграк англо-саксон (киңрәк алганда - протестант) традициясе дә бар. Билгеле бер мәгънәдә ул күпкә либеральрәк һәм индивидуаль сайлап алу өчен дә күбрәк ireккә хуҗа. Бу караштан караган вакытта, Европадагы "хиҗап мәсьәләсе" берҗенесле никахлар белән бер яссылыкта ята. Әгәр дә без сайлап алу хокукына либераль якын килү турында сөйлибез икән, каминг-аут хокукы белән хиҗап киеп йөрергә хокук арасында нинди принципиаль аерма бар соң?

АКШ белән Бөекбританиядәге мөселман хатын-кызлары мәктәптә хиҗап киеп йөрү мөмкинлегенә ия. Скандинавия илләрендә дә хиҗапка күпкә түземлерәк караш урнашкан. Мәсәлән, Норвегиядә мәктәптә генә түгел, ә армиядә вакытта да хиҗаптан йөрергә рөхсәт ителә. Шулай итеп, без дөньяви секуляр модельнең, дини символларны мәктәптә дә, башка дәүләт учреждениеләрендә йөртүне рөхсәт итеп тә, бик нәтиҗәле эшли алуын күрә алабыз.

## Сандал белән чүкеч арасында

Күрүебезчә, Көнбатышта хиҗап мәсьәләсен хәл итүнең ике төрле варианты яшәп килә: тыярга яки рөхсәт итәргә (төгәлрәге - тыймаска). Россиядә соңгы вакытларга кадәр яулыктан йөрү мәсьәләсе ул кадәр үк кискен тормады. Дөрес, башка бәхәсләр дә булмады түгел, булды. Мәсәлән, яулык бәйләп паспорт өчен фотосурәткә төшү турындагы бәхәс (анысы 2000 нче еллар башында күзәтелде). Бу дискуссияләрнең нәтиҗәсе буларак, Россиянең Югары Суды мөселман хатын-кызларына паспорт өчен фотога төшкән вакытта башларына бөркәнергә рөхсәт итте.

Урта мәктәптә мөселман яулыгын киеп йөрү турындагы бәхәснең бер үзенчәлеге бар. Университетлардан һәм башка дәүләт учреждениеләрендәгеләрдән аермалы буларак, мәктәптә кызлар, күпчелек очракларда, яулыкны ата-аналары йогынтысында бәйләп йөри. Укучы балаларның хиҗабы - ул аларның ата-аналарының карары. Шулай итеп, җиңелгән як, бу очракта, укучылар үзләре, алар сандал белән чүкеч арасында калган кебек, үз ата-аналары һәм дәүләт учреждениеләре арасында торып калалар.

Чынлап та, ата-аналар балаларына үз карашларына карап үзләре теләгәнчә тәрбия бирергә хокуклы. Әгәр дә инде бу кыз баланы берничә ел буе Ислам рухында тәрбияләгәннәр икән, яулыкны салырга мәҗбүр итеп, дәүләт аларның күңеленә психологик яра сала, аларга күңел яралары тәҗрибәсе (гаиләдә, өйдә авырлыклар килеп чыгу, индивидуаль проблемалар) өсти. Аннан тыш, мәктәптә яулыкны (шул исәптән, башка дини символларны да) дискриминацияләү - бу кызлар өчен мәктәптә нормаль дөньяви белем алу өчен юллар ябылган булуга да шартлар тудыра. Бу - гендерлыкка хас проблемалар буенча хәлне кискенләштермәсме соң?

Монда мөселман яулыгының динилекне гади бер демонстрацияләү генә түгел, ә аның шактый киң таралган ислам норма-күрсәтмәсе икәнен дә белү зарур. Бу балаларның ата-аналары шул күрсәтмәләр буенча эш итәләр дә. Шул уңайдан традиционалистлар (Исламның дүрт төп мәзһәбе тарафдарлары) һәм радикаль хәрефчеләрнең позицияләре бер-берсеннән әллә ни аерылмый. (Беренчеләре проблемага бераз йомшаграк, сыгылмалырак якын киләләр дип исәпләмәгәндә.)

## Хиҗап - Россия мәктәпләрендәге проблемаларның иң зурысы түгел

Ставропольдәге "хиҗап эше"-нең киң резонанс алуы бу вакыйганың илебез җәмгыятендә булган билгеле бер авыру нокталарына тиеп үтүен күрсәтте. Мәсәлән, илдә диннең тоткан урыны турындагы мәсьәләгә.

Ставропольдә килеп чыккан низаг нәтиҗәсендә Россиянең Мәгариф һәм фән министры Дмитрий Ливанов: "Мәктәп формаларына булган таләпләрне федераль дәрәҗәдә стандартлаштырырга кирәк", - дигән тәкъдим ясады.

Монда да билгеле бер каршылыклар бар. Аларны югары куелган кайбер дәүләт эшлеклеләренең сүзләрендә һәм гамәлләрендә күзәтергә туры килә, һәм бер аларныкында гына да түгел. Бер яктан алар, мөселман яулыклары турында сүз барган вакытта, мәктәпнең дөньяви характерда булуын искә алалар, ә икенче яктан, 2012 елдан башлап Россия мәктәпләрендә дин (православие, ислам, будда, яһүд) нигезләре укытылу мөмкинлеген китерәләр. Мәктәпнең дөньяви булуына кайсы күбрәк куркынычлырак соң: бу мәктәптә кыз балаларның яулык киеп йөрүләреме, әллә анда "Ходай сүзләрен" укытумы?

"Мәктәптә хиҗап" киеп йөрү проблемасы белән урта гомумбелем бирү уку йортларында дин нигезләрен укыту арасында параллель үткәрүне дәвам итеп, "Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре" предметында (элегрәк ул "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дип атала иде. - ред.) дини модульләрдән тыш, "Дөньяви этика нигезләре" курсын сайлап алу мөмкинлеге дә бирелгәнен әйтеп үтәсе килә. Мәктәптә кайсы модуль өйрәнелергә тиешлеген сайлап алу ата-аналар һәм балалар карамагында кала. Бу уңайдан шундый тәкъдим бар: дини символлар йөртү мәсьәләсен дә, шулай ук, аерым билгеле бер мәктәпнең ата-аналары хәл итәргә тиеш.

Бу мәсьәләне хәл итүдәге теләсә кайсы вариант кирәкмәгән, чамадан тыш зур шау-шулар китереп чыгарырга мөмкин. Андый мәсьәләләрне чишкән вакытта, илебезнең киң масштабларын һәм мәдәни күптөрлелеген исәпкә алып, бар факторларны да истән чыгармау зарур.

Чын дөресен генә әйткәндә, бездәге гомумбелем бирү мәктәпләрендә бүген хиҗап мәсьәләсе кабыргасы белән тормый һәм ул иң актуаль проблемаларның да берсе түгел. Җәмгыятебезнең һәм дәүләтебезнең бар көче Россия мәктәпләренең фундаменталь проблемаларын чишүгә юнәлтелергә тиеш.

Хәзерге Россиядә хиҗапның нәрсә символлаштыруын - традицион реакцияме, әллә заманчалыкны яңача (альтернатив) аңларга тырышумы икәнен аңлау өчен һәрбер очракны аерым тикшерергә кирәк. Хиҗап - катлаулы символ.

**Данис ГӘРӘЕВ,**
**"Ислам порталы" редакторы**

# ГАРАСАТ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

"Аерым үз сукмагы" һәм "кәҗә "характырының" кешенекенә караганда ныграк булуы... Әлеге сүзләр, инде хакыйкатькә әверелегән суpәттә, мине гомерем буе озата баралар...

Яшь чакта баштан кичкән һәм алда сурәтләнгән вакыйгалар фәлсәфәсен ул вакыттан бирле бер формага сала алмыйча азаплана идем. Хәзер аларны үзем өчен өр-яңадан ачып утырам: тормышның кайсы гына тармагын алып карама, яшьлектә тап булган хакыйкать кабат яңарып, шуларның кайтавазы баш миендә зыр-зыр әйләнә.

Күптән түгел машина рулендә авылга кайтып барышлый бер "шумахер" каршы юлга чыгып, чак кына авариягә эләкмичә калганнан соң, исән калу шатлыгыннан алдагы авылда ук туктап, мәчеткә сәдака кертәм дип нәзер әйткәнемне үзем дә сизми калдым. Җомга көн иде бу, намаз башланырга әле шактый вакыт бар, мәчет янында машинаны туктаткач, нәзеремне үтәргә ниятләп, эчкә кердем. Җомга намазына дип килгән авыл кешеләре инде мәчет эчендә, тыныч кына медер-медер сөйләшеп утыралар. Ни хакында сөйләшкәннәрен дә ишеттем: берсе дә авыл гайбәтен сөйләми иде, мулла бабай кулындагы китаптан пәйгамбәрләр турында кычкырып укып утыра, калганнар бик бирелеп тыңлый: намазга чаклы булган вакытны шулай үткәрә болар. Менә берзаман, - намаз башланырга күп калмаган иде инде, - ишек ачылып китте дә мәчет эченә, дөп-дөп басып, бер төркем яшьләр килеп керде. Дөп-дөп!.. Без сугыш киноларында гына күргән гестапочылармыни! Намаз тәмам булгач, янә шул рәвешле дөп-дөп басып, чыгып та китте болар. Иң әһәмиятлесе, мин шуңа игътибар иттем: болар мәчет картларына җирәнгеч, мыскыллы караш ташлап керделәр һәм шундый ук тәкъва кыяфәттә чыгып та киттеләр. "Ваhhабитлар" дип пышылдады кемдер алар артыннан. Мин юлымны дәвам иттем. Һәм күңелдә шул мизгелләрдә уянган канәгатьсезлек хисләре, үз чиратында, миндә төрле фикерләр уятып, әлеге хәлгә ике-өч җөмлә белән генә карашымны белдергәнем дә хәтердә: "Афәрин бу яшьләр! Дин тарихын яхшы үзләштергәннәр, ләкин үз тарихларын белергә теләмиләр! Әле кайчан гына башларына түбәтәй кигәннәре өчен дә "Милләтче! Кадимче!" дигән ярлык алган, изге рамазан айларында кача-поса намаз укыган, "гает намазы" дип тә авыз ача алмаган ата-бабалары, инде менә, шөкер, чак кына сулыш алып, мәчет катына килә алганнар икән, таһарәтләрен алырга җылы сулар әзерләп, аларның артларыннан сөенеп озатып калган хатыннары "әлифне таяк" дип белә башлаганнар икән! - бу хәтлесе дә алар өчен зур куаныч инде, балакайлар!"

*(Дәвамы киләсе саннарда.)*

# РОССИЯДӘ ХЕЗМӘТНЕҢ ТОРЫШЫ

**Әйдәгез, хезмәт кыйммәтләренең россиялеләргә, шул исәптән хәзерге Россия мөселманнарына туры килү-килмәү мәсьәләсен тикшереп карыйк әле.**

XX йөзнең туксанынчы елларында тормыш дәрәҗәсенең түбән төшүе белән, күп кенә ватандашларыбыз өчен хезмәт күңелгә хозурлык бирә торган эшчәнлек, үз-үзеңне реализацияләү чарасы, җәмгыятькә файда китерү ысулы, замандашларың алдында үзеңнең мораль бурычыңны башкару, пенсионерларның, инвалидларның һәм җәмгыятьтә мохтаҗлык кичергән башка төркемнәрнең тормышын тәэмин итү ысулы булудан туктап, үз-үзеңне тәэмин итүнең гади бер чарасына гына әйләнеп калды. Килеп туган бу вазгыять вакытында кешеләр нәтиҗәле һәм сыйфатлы хезмәткә омтыласы урынга, тиз арада күп хезмәт хакы бирә торган эшләр эзли башладылар. Ләкин бу мәсьәләдән чыгу юлы түгел иде. Чөнки барысына да битараф булган, якын арада һәм күп итеп хезмәт хакы эшләп алырга гына исәпләгән кеше үз эшенең остасы булу турында бервакытта да уйлап карамаячак. Ә бу исә бар Россия халкының квалификация югалтуына китерәчәк.

Узган гасырның 90 нчы елларында реформалар башлангач, Россия икътисады зур үзгәрешләр кичерде. Тулы бер тармаклар яшәп калу шартларында гына эшли башладылар. Һәм шуның нәтиҗәсе буларак, аларның эшләүчеләре, ярлылыкта калмас өчен, бер тармактан икенче тармакка күчеп йөри башладылар.

1991 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр Россия сәнәгате (промышленность) 35 % эш урыннарын югалтты. Материал җитештерүнең башка тармаклары да шуңа тиңдәш югалтулар кичерде: авыл хуҗалыгы - 30 процентка якын, төзелеш тармагы - 40 процентка якын, транспорт - 20 проценттан артык. Иң зур югалту фән өлкәсендә булды: фәнни хезмәткәрләрнең саны ике тапкыр диярлек кимеде. Аның урынына яңа эш урыннары башка тармакларда барлыкка килде, алар сәүдә өлкәсендә - 100 процентка, финанслар даирәсендә - 130 проценттан күбрәк, дәүләт идарәсендә 100 процентка артты. Россия өчен, тулаем алганда, яхшымы соң бу?

Ислам күзлеге буенча, ике тапкыр галимнәр саны кимүен һәм шул ук вакытта ике тапкырга түрәләрнең артуын ничек бәяләргә? Җәмгыятькә бу төркемнәрнең кайсыларыннан файда күбрәк тия?

Хезмәт хакының төбәкләр арасында аермасы зур булу Россиянең үз эчендә кешеләрнең күпләп күченеп йөрүенә китерде. 1991 еллардан исәпләп карасак, Россиядә 50 млн кеше үзләренең яшәү урыннарын үзгәртте, бу - бар ил халкының өчтән береннән дә артык. Кешеләр гадәттә Мәскәүгә, Санкт-Петербургка, Хант-Манси - Югра автономияле округына һәм башка төбәкләргә күченеп киттеләр.



Шәһәр белән авыл арасындагы хезмәт хакында шактый күп аерма авыл җирлегеннән һәм зур булмаган шәһәрләрдән зур шәһәрләргә, мегаполисларга хезмәт миграциясен арттырды.

Әмма Ислам күзлегеннән караган вакытта, кешеләрнең үз гаиләләрен тәэмин итәргә һәм ярлыланмаска тырышуы хуплана торган эш.

XX гасырның туксанынчы еллары башында Татарстан Республикасында хезмәт, гаилә, хакимият, матди яктан тәэмин ителгәнлек, дуслар, буш вакыт һ. б. шуңа охшаш тормышның төрле даирәләренең кайсысы мөһимрәк икәнлеген ачыклау буенча сораштыру үткәрелгән иде. Ул вакытта хезмәт (гаилә һәм матди яктан тәэмин ителгән булудан кала) өченче урында иде. 2000 еллардагы сораштырулар буенча, хезмәт, "башкаларның хөрмәтенә лаек булу"га урын биреп, дүртенче урынга төшеп калды.

Бу нәрсә турында сөйли соң? Ул без яшәгән җәмгыятьне ни рәвешле сыйфатлый? Шундый фараз китерергә була: димәк, кешеләр, эш һәм хезмәт кую аларның матди хәле һәм башкаларның хөрмәтенә лаек булу белән артык бәйле түгел икәнлегенә һаман да күбрәк төшенә баралар. Ә кешеләргә карата мондый караш динебез белән артык бәйле түгел.

***Галим ВАХИТОВ,***
***икътисад фәннәре кандидаты,***
***Россия ислам университетының Ислам икътисады һәм идарәсе кафедрасы мөдире***

# Сөйләм әдәбе

**Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм эшемне, чын мактау бары тик Аллаһы Тәгаләгә тиешле, Аллаһның Рәсүленә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын! Аллаһ безнең барыбызны да Үзе сөйгән һәм Үзенең ризалыгына ирештерә торган юлга күндерсен!**



Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яхшы сөйләм сәләтенә ия булган, аның белән аралашу үзе бер хозурлык булган. Ул (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) иң матур, иң назлы, иң йомшак, иң яхшы сүзләрне генә сайлап сөйләшкән. Әгәр кем дә булса Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) берәр сүзен икенчегә, аннан яхшыракка дип уйланылганына алмаштырырга теләсә, моны эшләү мөмкин булмас иде, чөнки сөйләмнәрнең иң гүзәле - Пәйгамбәребезнеке (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!). Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Бәндәләремә әйт, иң татлы сүзләр генә сөйләсеннәр. Чөнки шайтан аларның арасында гауга чыгаручы. Һичшиксез, шайтан - кешенең иң хәтәр дошманы" ("Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары)" сүрәсенең 53 нче аяте), - дигән.

Биредә "Яхшы сүзләр кулланып кына сөйләшегез, югыйсә, шайтан сезнең сүзләрегездән файдаланып, сезне хәл итеп булмаслык мәсьәләләр алдында калдырачак", - дип әйтә кебек. Чыннан да, кешеләрнең күп кенә борчу-мәшәкатьләре яман сүзләр кулланудан килеп чыга. Кемдер ниндидер бер сүз әйтеп куя, ә икенчесе исә моны үзенчә кабул итә һәм дә үзара аңлашылмаучанлык килеп туа. Аннан соң, янәсе: "Ул дөрес аңламаган", - дип әйткән булалар.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзара каршы тору һәм дошманлашу мөнәсәбәтләрендә булган кяферләр белән аралашкан һәм гәпләшкән вакытта да, Коръәндә бу хакта искәртелеп китүе буенча: "Әйт син:

- Без кылган гөнаһларга сез җаваплы түгел, - диген. Без дә сез кылганнар өчен җавап бирмәбез" ("Сәбә (Сәбә иле)" сүрәсенең 25 нче аяте), - дип әйтеп, алар белән яхшы мөгамәләдә калырга тырышкан.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) кяферләргә: "Әгәр дә сез безне ялгышалар дип шикләнәсез икән, безнең ялгышлар өчен сездән сорамаячаклар. Һәркем үзе кылган өчен үзе җавап тотачак", - дигән, хәтта аларга да хөрмәт белән карап: "<...> сез кылган гамәлләрегездән без соралмабыз", - дигән. Ягъни Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аларны гөнаһ кылуда шикләнү күрсәтеп, кычкырып әйтмәгән.

**(Дәвамы киләсе санда.)**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 17.11.12 | 6:53 | 8:23 | 13:02 | 15:23 | 16:33 | 18:03 |
| Якшәмбе | 18.11.12 | 6:55 | 8:25 | 13:02 | 15:21 | 16:31 | 18:01 |
| Дүшәмбе | 19.11.12 | 6:57 | 8:27 | 13:02 | 15:21 | 16:30 | 18:00 |
| Сишәмбе | 20.11.12 | 6:59 | 8:29 | 13:02 | 15:19 | 16:28 | 17:58 |
| Чәршәмбе | 21.11.12 | 7:01 | 8:31 | 13:02 | 15:19 | 16:27 | 17:57 |
| Пәнҗешәмбе | 22.11.12 | 7:03 | 8:33 | 13:02 | 15:17 | 16:25 | 17:55 |
| Җомга | 23.11.12 | 7:05 | 8:35 | 13:02 | 15:17 | 16:24 | 17:54 |
| Шимбә | 24.11.12 | 7:07 | 8:37 | 13:02 | 15:16 | 16:23 | 17:53 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 20 (163) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9425.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 15 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**